ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2018 г.Мензелинск № 1384

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының 2015 елның 18 маендагы “Олимп” “Балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесе исемен үзгәртү һәм Уставын раслау турында”гы №441 Карарына үзгәрешләр кертү турында**

08.10.2018 елда кабул ителгән “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль казна учреждениеләре уставларына (нигезләмәләргә), мәнфәгатьләр каршылыгына китергән һәм китерергә мөмкин булган хезмәт вазифаларын башкарганда шәхси кызыксынучанлык килеп чыгу турында хәбәр итү бурычын билгеләүче тиешле учреждение (предприятие) җитәкчеләре һәм анда эшләүчеләр тарафыннан хезмәт килешүләренә мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен җайга салучы үзгәрешләр кертү турында”гы №1136, шулай ук 25.12.2008 елдагы “Коррупциягә каршы тору турында”гы №273-ФЗ Федераль Законы нигезендә, Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1.”Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Олимп” балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” өстәмә белем бирү Муниципаль бюджет учреждениесе Уставына үзгәреш кертергә:
“Өстәмә белем учреждениесе белән идарә итү тәртибе” V бүлеген “Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу” 5.33 пункты белән тулыландырырга.

5.33.1 Учреждение хезмәткәренең хезмәт вазифаларын тиешенчә үтәвенә тәэсир итәрдәй һәм хезмәткәрнең кызыксынучанлыгы һәм учреждениенең хокуклары һәм үзе эшли торган учреждениенең законлы

мәнфәгатьләре арасында килеп чыгарга мөмкин булган, мөлкәткә һәм учреждениенең эшлекле репутациясенә зыян китерүгә сәләтле каршылык тудыручы ситуация мәнфәгатьләр каршылыгы дип аңлашыла.

5.33.2. Учреждение хезмәткәренең вазифаи бурычларны үтәү белән бәйле рәвештә үзе яисә өченче затлар өчен акчалата, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт рәвешендә, шулай ук мөлкәткә хокуклар һәм мөлкәт характерындагы хезмәтләр алуы вазифаи бурычларны тиешенчә үтәүгә тәэсир итә һәм тәэсир итә алу мөмкинлеге учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы дип кабул ителә.

4.9.3. “Олимп” балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” МБУ директоры вазифаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче һәм китерү мөмкинлеге булган шәхси кызыксыну килеп чыгу турында ТР Минзәлә муниципаль район Җитәкчесенә хәбәр итәргә бурычлы.

4.9.4. “Олимп” балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” МБУ хезмәткәре вазифаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче һәм китерү мөмкинлеге булган шәхси кызыксыну килеп чыгу турында учреждение директорына хәбәр итәргә бурычлы.

4.9.5. “Олимп” балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” МБУ директорына хәбәр итү, хәбәр язуында булган мәгълүматлар, әлеге мәгълүматларны тикшерү һәм әлеге хәбәрләрне теркәү тәртибе “Олимп” балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” МБУ директоры тарафыннан билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Олимп” балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” МБУ директоры Ч.Р..Харисованы “Олимп” балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертүне уздыру буенча вәкаләтле итеп билгеләргә.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны мәгариф, мәдниятия, сәламәтлек саклау, яшьләр эшләр, спорт һәм социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

ТР Минзәлә муниципаль
Район Башкарма комитеты
Җитәкчесе вазифаларын башкаручы А.Г.Гатина.